## Ономастика буенча язылган хезмәтләрдә этнолингвистик мәсьәләләр

Хәзерге тел белемедә кеше тормышы белән тыгыз бәйләнештә торган ономастиканы теоретик яктан фән буларак нигезләү катгый таләпләрнең берсе буларак кабул ителә, чөнки ономастик дөнья картинасында һәрбер кешенең, ягъни исем кушучының, һәрбер этносның мәдәниятендәге төп сыйфатлар чагылыш таба. Әмма фән өчен бу фактның барлыгын тану гына иҗтми, ә теге яки бу халыкның ономастиконыннан тарихи-мәдәни мәгълүматны “сөзеп” алу, аны тиешенчә тасвирлау һәм ачыклап-аңлатып бирүнең үз методологиясендә эшләргә кирәк. Мәгълүм булганча, мәдәни-тарихи мәгълүмат төшенчәсе бертөрле генә аңлашылмый, ул үзара тыгыз бәйләнештә торган берничә өлешне – милләт тарихы, иҗтимагый тормыш, халыкның матди тормышы һәм рухи мәдәнияте турындагы мәгълүматларны үз эченә ала. Беренче өч төр мәгълүмат телдә, шул исәптән ономастикада да шактый тулы яктыртыла (әлбәттә, аларны ачыклау-аңлатуда үзенең авырлыклары бар, аеруча милләт тарихына кагылышлы мәсьәләләр булса), ә дүртенчесе, ягъни рухи мәдәният турындагы мәгълүматлар чагыштырмача тонык күзаллана, ул фактик материал туплау һәм аны эшкәртү тәртибенең тиешенчә эшләнгән булуын таләп итә. Бу төр мәгълүматлар белән, беренче чиратта, *этнолингвистика* фәне эш итә. Этнолингвистика – ул “телне кеше аңы, аның менталитеты, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, халыкның мифологик күзаллаулары һәм рухи иҗаты аша өйрәнә торган дисциплина” (Толстой, Толстая, 1995, 5), икенче төрле итеп әйткәндә, бу фән тармагы “милләтнең традицион рухи мәдәниятен һәм аның телдәге чагылышын тикшерә” (Шунда ук 488). Этнолингвистика фәненең предметы турында шактый тулы күзаллау тудыра торган әлеге билгеләмәне тел белемендә иң дөресе дип санарга мөмкин, чөнки бу юнәлештә олы бер фәнни мәктәп (академик Н.И. Толстой мәктәбе) эшли. Аннары әлеге билгеләмә кысаларында этнолингвистика фәненең предметы социолингвистика,

психолингвистика кебек башка катнаш дисциплиналардан аерылып, чагыштырмача ачык күзаллана башлый (дөрес, биредә аларның үзара тәэсирен һәм керешүләрен дә онытырга ярамый). Нәтиҗәдә, әлеге фәннең предметын шулай тарайтып аңлату, күренекле галим А.С. Герда тарафыннан шактый тулы бирелгән билгеләмәгә караганда, күпкә отышлырак килеп чыга. А.С. Герда хезмәтләренә караганда, “этнолингвистика предметы – ул телнең милләткә, милләтнең телгә карата мөнәсәбәте”. Галим фикеренчә, тел үзенең төрле яшәеш формаларында, үз үсешенең төрле чорларында халык тарихына, милләтнең җәмгыятьтә тоткан урынына ничек итеп тәэсир иткән һәм бүгенге көндә йогынтысы ни дәрәҗәдә - шушы проблемаларны ачыклау этнолингвистиканың максаты булып тора (Герд, 1995, 3, 5).

Иң элек термин мәсьәләсенә тукталыйк. Шунысын танырга кирәк: бүгенге көндә ономастика буенча язылган хезмәтләрдә *этнолингвистика* термины Н.И. Толстой мәктәбенең фәнни эшләрендә чагылыш тапкан мәгънәдә кулланылмый диярлек. Соңгы ун ел эчендә әлеге термин ономастик әдәбиятта ике төрле мәгънәдә аңлатыла башлады. Беренчедән, этнолингвистик анализ дигәндә, еш кына топонимнарны аерым бер милләтнең тел фактлары буларак тикшерүне күзалдында тоталар. Бу очракта фәнни тикшеренү максаты булып, топонимнарны этнолингвистик яктан стратификацияләү, ягъни теге яки бу тирәлектәге топонимик континуумда төрле милләткә караган топонимияне аерып чыгару тора (мәсәлән, Арсланов 1992; Афанасьев 1989; Черепанова 1991). Бу күренешне шушы яссылыкта аңлату этнолингвистик аспектны этногенетик аспектка кайтарып калдыра (бер яктан караганда, этнолингвистик анализның асылын болай аңлату да дөрес кебек). Топонимик әдәбиятта *этнолингвистик тикшеренү* терминының башка мәгънәдә кулланылышы да күзәтелә. Бу очракта *этнотопонимнарны, ягъни этнонимнардан барлыкка килгән берәмлекләрне табу һәм аларның мәгънәсен ачыклап-аңлатып бирү* күз алдында тотыла (Этническая топонимика 1987, 3; Мусабекова 1987 һ.б.).

Шулай итеп, *этнолингвистика* терминын аңлауда ономастика белән “аппелятив” тел белемендә фикер төрлелеге яшәп килә. Тиешле термины булмауга карамастан, күп кенә хезмәтләрдә этнолингвистик максатлар куела. Бу, беренче чиратта, ялгызлык исемне анализлаганда иң элек милли-мәдәни семантиканы ачыклауга (“лингвострановедческий подход”) өстенлек биргән хезмәтләрдә күзәтелә (Аникина 1988; Беля, Зайченко 1989; Бирилло 1995; Бондалетов 1993; Верещагин 1991; Леонович 1991; Митрофанов 1992; Ощепкова 1995; Томахин 1989, 1991; Шабанова 1994).

Милли-мәдәни семантикага өстенлек бирү дигәндә, “теге яки этномәдәни-тел бердәмлегенә кергән һәммә кешенең аңында объективлаша торган синхрон күзаллаулар тупланышы, шул күзаллауларның башлангыч ноктасы” буларак карала торган барлык мәгълүматларны да ачыклау күз алдында тотыла. Мондый караштан чыгып эш итү, беренчедән, тикшеренүгә икеләтә синхрон төсмер бирә, икенчедән, бу очракта барлык ономастикон да түгел, ә милли мәдәният өчен аеруча зур әһәмияткә ия булган берәмлекләр генә алына. Андый берәмлекләрнең мәгънәсе “милли аңга салынган типик образ” белән билгеләнә (Ощепкова 1995: 24). Мондый төр онимнарны башкача *реалий-исемнәр* дип тә атыйлар (Шунда ук).

Исемнәр башка төр ономастик континуумга каршы куела: “Җирле топонимиягә кагылышлы мәгълүмат тирә-юньдәге кешеләрдән алынса, лингвомәдәни фонга карый торган белемнәр мәктәп, вакытлы матбугат, массакүләм мәгълүмат чаралары аша кабул ителә” (Томахин 1989, 83 – 84). Галимнәр игътибарга алган кайбер шундый ономастик фактларга мисал итеп түбәндәгеләрне китерергә мөмкин: *Робин Гуд, Биг Бэн* (Бөекбритания өчен), *Нэд Келли, Фар Лап* (Австрия өчен), *Мәскәү, Степан* Разин (Россия өчен). Болардан тыш, әдәби ономастика фактларының тәэсирен дә искәртергә кирәк: *Чевенгур, Глупов шәһәре, Буян утравы, Илья Муромец* (Верещагин 1991, 46; Шабанова 1994).

Теләсә кайсы төрдәге этнолингвистик тикшеренүләрнең үзәгендә милли-мәдәни үзенчәлекләрне ни рәвешле итеп чагылдыру мәсьәләсе тора.

Лингвострановедения фәнендә бу бурычны исемнең фон семантикасы башкара. Кайбер билгеләмәләргә караганда, исемнең фон-коннотатив мәгънәсе – ул “милли мәдәнияткә бәйле булган һәм үзендә аерым бер тел коллективы кысаларындагы сөйләм һәм контекст билгеләмәләренең кушылмасын чагылдыра торган җыелма” (Аникина1988, 7). Рус антропонимнарын шушы яссылыкта тикшергән М.Н. Аникина хезмәтләрендә фон-коннотатив мәгънәнең чагыштырмача тулы тасвирламасы белән очрашабыз. Ул үз эченә дүрт компонентны ала: формаль, ситуатив, иҗтимагый-тарихи, индивидуаль-күзаллаулы. *Формаль компонент* сүз эчтәлегенең системалы чагылышы булып тора, *ситуатив компонент* исә үз эченә субъектив бәяләү һәм стилистик кулланылыш коннотацияләрен ала, *иҗтимагый-тарихи компонентка* мәдәни-тарихи күзаллаулар кертелә, *индивидуаль-күзаллаулы компонент* исә шушы телдә сөйләшүченең аңында тарихи шәхесләр, әдәби геройлар белән бәйле күпсанлы ассоциацияләрнең булуын таләп итә (Аникина 1988, 7-9).

Әмма, кызганычка каршы, бүгенге көндә ялгызлык исемнәрнең идиоэтник үзенчәлекләрен ачыклауны максат итеп куйган хезмәтләр юк дәрәҗәсендә. Мәгълүм булганча, исемнең идиоэтник үзенчәлекләре исә үз чиратында ономастиконны туплауның иң тирән конструктив принципларын тикшерүгә нигезләнә. Мәсәлән, этнолингвистик мәсьәләләрне нәтиҗәле хәл итеп килә торган А.Ф. Журавлев антропонимнарның шактый үзенчәлекле төркемен – *төбәк-территория кушаматларын* анализлый һәм түбәндәге нәтиҗәләргә килә: “микроэтнонимиянең мотивлашу нигезе булып хезмәт итә торган үзенчәлекләр җыелмасы бар. Бу җыелма этнография фәне объектының үзе тарафыннан эшләнә торган рубрикация, ягъни этноиҗтимагый тирәлекнең аерым өлешләргә бүленеше һәм шуның белән бергә этник тиңләштерелүнең конкрет нигезе буларак каралырга тиеш” (Журавлев 1995, 51). Үзенең икенче бер хезмәтендә автор исемиятне антропонимиянең халык аксиологиясен чагылдыра алу мөмкинлегенә бәйләп тикшерә. Бу очракта ул славян антропонимиконының багышлау һәм

теләк исемнәренә мөрәҗәгать итә, аларның шушы милләткә генә хас мәдәни кыйммәтләр белән тыгыз бәйле булган, идиоэтник чараларда башкача аңлашыла торган компонентларын аерып чыгара (*bog-, bolg-, dobro-, dom-, dorg-, gъrd-, xval-, lub-, mil-, mir-, mysl-, vold-* һ.б.) (Журавлев 1993, 114).

Әлеге мәсьәләне тикшерүгә Т.В. Топорова да үзеннән зур өлеш кертә. Ул алман халкының дөнья картинасына бәйле булган, ике кисәктән торган борынгы алман исемнәрен анализлый. Ономастик материалга мөрәҗәгать итүенең сәбәпләрен автор болай дип аңлата: *monima propria* дөньяның мифопоэтик моделендә төп урынны били, чөнки алар кешенең табигать белән бәйләнешен чагылдыра торган символлар булып торалар (Топорова 1996, 6). Дөнья картинасына чыгу нигездә төп семантик өлкәләрне ачыклау аша тормышка ашырыла. “Даирә һәм вакыт”, “Космология”, “Әйберләр дөньясы”, “Иҗтимагый-юридик” һ.б. шундый семантик өлкәләргә ике кисәктән торган антропонимнарның аерым компонентлары да керә. Нәтиҗәдә, дөнья моделенә хас үзенчәлекле билгеләр аерып күрсәтелә: *мифологияләштерү* (онома компонентларын борынгы мифопоэтик аңдагы каршылыклы карашлар нигезендә аныклау, мәсәлән, *минеке - ятныкы*), *идеаллаштыру* (уңай сыйфатларны ассызыклап, тискәреләрен яшерү), *геройлаштыру* (героик поэзиянең кеше исемнәре барлыкка килүгә, аларның мәгънәсенә тәэсир итүе) (Шунда ук). Ике өлештән торган иске алман исемнәрен славян, балтик, грек һәм башка индоевропа телләрендәге ялгызлык исемнәр белән чагыштырып тикшерү дә әлеге хезмәтнең дәрәҗәсен сизелерлек күтәрә. Әлеге анализның төп нәтиҗәсе булып, дөнья моделе төзелешенең сызымнары тора. Алар өч индоевропа ареалында кулланыла торган ике кисәкле ялгызлык исемнәрнең аерым өлешләреннән төзелгән.

М.Э. Рут үзенең хезмәтләрендә, урбанонимия белән чагыштырганда, күпкә катлаулырак (исем бирү субъектын билгеләү күзлегеннән караганда) булган материалга – рус халык ономастикасына күчә. Ул үз алдына халыкның (бу очракта төньякта яшәүче рус крестьяннарының, чөнки

хезмәттә Төньяк илләрдәге рус халкының топонимиясе, антропонимиясе һәм астрономиясе тикшерелә) дөнья картинасын тергезү максатын куя. Автор барлык ономастик берәмлекләрне дә тикшерү объектны итеп алмый, ә бары тик образлы номинацияләү нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәренә генә игътибар итә. Чөнки андый төр онимнарда "исемнең объекты һәм субъекты турында мәгълүмат тупланган була" һәм " халык аңында тарихи барлыкка килгән дөнья картинасы номинацияләрен саклау ягыннан караганда да алар милли үзенчәлеккә ия" (Рут, 1992, 45). Автор дөнья картинасын тасвирлауның үзенчәлекле юлын тапкан: образлы тәңгәлләштерү модельләре образлы предмет өлкәләреннән торган иерархиягә салына: "Кеше", "Гаилә", "Өй һәм өйалды", "Авыл", "Турыдан-туры бәйләнештә булган табигать (урман, елга)", "Тышкы дөнья" (Шунда ук, 52). Әлеге өлкәләрне үзара каршы куеп тикшерү аша (Мәсәлән, "Өй" өлкәсенең өстенлеген, "Тышкы дөнья" тармагының чагыштырмача пассив булуын ачыклана) галим шундый нәтиҗәгә килә: образлы милли система "дөнья = өй" концептуаль моделенә нигезләнгән (Шунда ук, 128). Шулай итеп, образлы номинацияләүнең "Игенчелек" төре турында да сүз алып барырга мөмкин булып чыга. Субъектларны концептуаль аныклау динамикасының шактый кызыклы һәм нәтиҗәле булуын да искәртергә кирәк. Автор фикеренчә, беренчел атау моделе мифологик дөнья картинасына нигезләнгән, ә мифологик дөньяда, белгәнебезчә, кеше белән табигатьнең тәңгәллеген чагылдыра торган кеше һәм хайвансыман образлар өстенлек итә. "Әлеге башлангыч образларны эшкәртү кешенең хуҗалык эшчәнлеген тулырак яктырту ягына борыла. Шуның нәтиҗәсендә "табигать – кеше" моделе әкеренләп "табигать – кешенең хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсе" дигән юнәлешкә йөз тота. Образлы өлкәләрне төгәлрәк тасвирлау әкеренләп гомуми космологик картинаны кисәкләргә бүлгәләүгә китерә, аны гносеологик яктан мөһим эталоннарның җыелмасына әйләндерә. Христианлашу нәтиҗәсендә дә беренчел мифологик дөнья моделенең концептуаль нигезләре күпмедер дәрәҗәдә юкка чыга, ә аннан соң барлыкка килгән образ-модельләр исә автоматик үсештә генә

булалар (шунда ук, 97 – 98). Димәк, әлеге хезмәтнең яңалыгы бар дип әйтми мөмкин түгел, чөнки аңарда ономастиканы концептуаль берләштерүнең төп закончалыклары карала. Ә бу үз чиратында кеше исемнәрендә чагылыш тапкан рухи мәдәният элементларын гына теркәп калмый, ә аларның интерпритацияләнгән моделен төзү мөмкинлеген дә бирә.

Кеше исемнәрен рухи мәдәният белән бәйләп өйрәнү М.В. Голомидова хезмәтләрендә дә чагылыш таба (Голомидова, 1998). Әлеге хезмәт этнолингвистик тикшеренүләрдән шактый ерак торган ясалма ономастика материалына нигезләнгән булуга карамастан, биредә “оном" концептының эшләнмәләре чагылыш таба. Бу җәһәттән, хезмәттә фрейм семантикасы кебек компонентның булуын да искәртергә кирәк. Мәсәлән, антропонимның кайсы милләткә каравын билгели торган фреймалар, йола фреймалары, эшләрне уңышлы башкаруның иҗтимагый шартларын билгели торган (мәсәлән, шулар тәэсирендә 1917 елгы инкыйлабтан соң фамилияләрне алыштыру актлары) иҗтимагый мимикрия фреймалары була (Голомидова 1998, 23 – 27). Әлеге хезмәттә тикшерелә торган онимнар, ягъни топоним белән антропонимнар һәм лингвистик, һәм менталь яссылыкта тикшерелә, ономастик номинациянең үсеше мәдәният тарихы контекстында карала. Шулай ук биредә ялгызлык исемнәрне “антропоцентрик” юнәлештән чыгып тикшерү дә чагылыш таба.

Ялгызлык исемнәрне тарихи-мәдәни яктан тикшерү традицияләре хәзерге тел белемендә инде төгәл билгеле, ачыкланган дип санарга мөмкин. (Агеева 1989; Бабичева, Черепанова 1992; Барбеков 1996; Карабан 1993; Картавенко 1993; Керимбаев 1991; Климкова 1990; Кондратова, Фещенко 1993; Косничану 1993; Мамонтова 1993; Мамонтова, Муллонен 1993; Мурзаев 1996; Успенский 1989; Щетинин 1993 һ.б.). Әлеге юнәлешнең яхшы үсеш алуына лингвистик һәм тарихи-мәдәни юнәлештәге сүзлекләрнең барлыкка килүе дә тәэсир итми калмагандыр. (Матвеев 1987, 1990, 1997; “Русская ономастика и ономастика России” 1994). Ялгызлык исемнәрне тарихи-мәдәни яссылыкта тикшерүне бурыч итеп куйган галимнәр, кагыйдә

буларак, ономастиконда матди мәдәният, тормыш-көнкүреш, иҗтимагый мөнәсәбәтләр һ.б. белән бәйле үзенчәлекләрне чагылдыру проблемаларына да тукталалар. Барыннан да бигрәк халыкның рухи мәдәнияте турындагы мәгълүматларны топонимиядә яңарту мәсьәләсенә галимнәр чагыштырмача сирәк мөрәҗәгать итә. Әлеге проблеманың этнолингвистик тикшеренүләрдә фәнни объект булып торуын да онытырга ярамый. Мәсәлән, этнографик топоним терминына таянып эш итүче Д.Р. Әмирова әлеге төркемгә түбәндәге атамаларны кертә: а) асыл сыйфатлардан ясалган этнографик топонимнар; б) этноним һәм патронимнардан барлыкка килгән этнографик топонимнар; в) халыкның дини һәм мифологик карашларын чагылдыра торган сүз һәм терминнардан ясалган этнографик топонимнар; г) этнографик зоотопонимнар; д) этнографик фитотопонимнар; е) җәмгыятьтәге иҗтимагый урынны һ.б. мәгънәләрне белдерә торган кеше исемнәре һәм кушаматларыннан барлыкка килгән этнографик топонимнар (Әмирова, 1992, 9 – 15). Әлеге исемлек ономаст галимнәр тарафыннан традицион аерып күрсәтелә торган “мәдәни” темалар җыелмасына туры килә. Мондый хезмәтләрнең югары кыйммәтен һәм мәсьәлә болай куюның әһәмиятен тагын бер кат ассызыклыйбыз. Әмма шуңа да карамастан, рухи мәдәниятнең матди мәдәният кануннары нигезендә тикшерелергә тиеш түгеллеген дә искәртергә телибез. Чөнки матди мәдәният конкрет лексик төркемнәргә берләштерелә торган конкрет күренешләр белән эш итә, рухи мәдәният исә дөнья картинасының нигезләрен барлыкка китерә. Шуңа күрә *monima propria*ны этнолингвистик яссылыкта тикшерү бер яки ике лексик төркемгә барлауга гына кайтып калырга тиеш түгел, ә исемнәр дөньясы барлыкка килүнең концептуаль нигезләренә ачыклауга да тукталырга кирәк.

Бүгенге көндә ялгызлык исемнәрне этнолингвистик яссылыкта тикшерү әле башланып кына килә. Ономастик тикшеренүләрнең әлеге аспектын һәм теоретик, һәм методологик яктан тиешле дәрәҗәдә эшләнгән дип әйтеп булмый. Кыскасы, “онимнарны этнологик яктан тикшерү юнәлешендә эшләр әле бик аз башкарылган” (Копыленко 1995, 58). Берничә

хезмəттə күтəрелгəн бер генə этнолингвистик мəсьəлəне əйтеп китəргə мөмкин: ул – мифологик (дини) күзаллауларның ономастикада чагылыш табуы (Летова 1988; Минкин 1993; Муллонен 1991, 1995; Мурзаев 1993; Теребихин 1991; Толстой 1989). Ономаст галимнəрнең этнолингвистик проблемаларны хəл итүдəге “басынкылыгы” аларның тезис рəвешендə генə язылган хезмəтлəрендə дə ачык күренə.

Шул ук вакытта ономастика һəм этнолингвистика фəннəренең “бер-берлəренə кирəк” булуын да искəртми мөмкин түгел. Бер яктан караганда, ономастик материал этнолингвистик анализ методикасын камиллəштерүдə яхшы этəргеч булырга да мөмкин. Чөнки этнолингвистик анализның методик дөреслеге экстралингвистик һəм лингвистик яктан раслана. Эктсралингвистик як дигəндə, номинация объектларының аерым бер тирəлеккə беркетелгəн булуы, теге яки бу территория топонимиясен барлыкка китерүчелəрнең этник һəм иҗтимагый бердəмлеге күз алдында тотыла. Лингвистик яктан исə узуальлəштерү нормаларының эшлəнгəнлеген, тикшерелə торган материалның югары дəрəҗəдə модельлəшүен, топонимнарга традиционлык хас булуын искəртергə кирəк. Икенче яктан караганда , этнолингвистик тикшеренүлəр топонимияне семантик яктан өйрəнүне камиллəштерү һəм яңарту өчен зарур, чөнки “отапеллятив” төркемлəү үсештəн тукталып калды. Шуның нəтиҗəсе буларак кайбер ономаст галимнəр бүгенге көндə “ономастика фəненең көчле үсеше бер урында таптанып тору белəн алмашынды” дигəн фикергə килə (Гусынина 1996, 238).